КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 23 август г.Казань № 1005

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре» 2012 ел, 10 март, 202 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре» 2012 ел, 10 март, 202 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 13 октябрь, 852 нче; 2013 ел, 18 март, 176 нчы; 2013 ел, 31 октябрь, 829 нчы; 2014 ел, 18 апрель, 257 нче; 2014 ел, 10 июль, 481 нче; 2015 ел, 21 гыйнвар, 25 нче; 2016 ел, 26 июль, 508 нче; 2016 ел, 19 август, 575 нче; 2017 ел, 10 ноябрь, 859 нчы; 2018 ел, 10 май, 340 нчы; 2019 ел, 3 апрель, 262 нче; 2019 ел, 16 июль, 588 нче; 2020 ел, 25 июнь, 525 нче; 2021 ел, 2 март, 110 нчы; 2021 ел, 6 декабрь, 1171 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1502 нче; 2023 ел, 17 март, 267 нче; 2023 ел, 9 июнь, 705 нче; 2023 ел, 24 июль, 881 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктта:

3.3.42 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.42. Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән очракларда хайваннарны исәпкә алуны гамәлгә ашыра;»;

түбәндәге эчтәлекле 3.3.43 һәм 3.3.44 пунктчалар өстәргә:

«3.3.43. Объектларны сакланылмаган объектларга яки зоосанитария ягыннан саклау дәрәҗәсе түбән булган объектларга кертеп караганда – объектларның – физик

һәм юридик затлар тарафыннан ветеринария контролендә (күзәтчелегендә) тотылырга тиешле хайваннар үстерү, асрау һәм чалу, товарлар җитештерү, эшкәртү һәм саклау эшчәнлеген гамәлгә ашыруда файдаланыла торган җир кишәрлекләренең, биналарның, бүлмәләрнең, төзелмәләрнең, корылмаларның зоосанитария статусын («Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $19^2$ статьясындагы 2 пунктының 3 бүлегендә күрсәтелгән очраклардан тыш) билгели;

3.3.44. Билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Рәисенең норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары белән каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

4.1 пунктның сигезенче абзацында «карап тикшерү өчен хайваннарны» сүзләрен «карап тикшерү һәм исәпкә алу өчен хайваннар янына керү мөмкинлеген (йорт янындагы җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан торак урыннарга керү мөмкинлегеннән тыш)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карар 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин